| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.05.2020 Зур Тигәнәле авылы № 150

**«Җир салымы турында» 2018 елның 16 ноябрендәге 105 номерлы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән Россия Федерациясе Салым кодексының 395 маддәсе нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар кылды:**

1. «Җир салымы турында» 2018 елның 16 ноябрендәге 105 номерлы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) дини оешмалар - дини һәм хәйрия билгеләнешендәге биналар, төзелешләр һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләренә карата».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет челтәрендә рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Алексеевский районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы 17 йорт; “Әшнәк” кибете бинасында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Алексеевский районы, Әшнәк авылы, Х.Вахит урамы, 11 йорт махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.З.Әхмәтҗанов**